КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август г.Казань № 829

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасында транспорт чараларының аерым төрләре мониторингының бердәм системасы турында» 2010 ел, 22 сентябрь, 754 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасында транспорт чараларының аерым төрләре мониторингының бердәм системасы турында» 2010 ел, 22 сентябрь, 754 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 июнь, 397 нче карары белщән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән 1 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«каты коммуналь калдыкларны чыгаруны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары;

өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары укучыларын йөртүне гамәлгә ашыра торгна автобуслар;

юл-төзелеш техникасы;

авыл хуҗалыгы техникасы;

урман патруле, урман янгыннары һәм урман хуҗалыгы техникасы;

автолавкалар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин